РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Каенлинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423560, Нижнекамский район,
с. Каенлы, ул. Ленина, 44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге
Советы

423560, Түбән Кама районы,
Каенлы авылы, Ленин урамы, 44

тел./факс (8555) 44-91-26, электронный адрес: Kaenlinskoe.sp @tatar.ru, сайт: www. kaenlinskoe-sp.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 25 июленнән № 9

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Каенлы авыл җирлеге Советының
2014 елның 30 октябрендәге
20 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Каенлы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Каенлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 октябрендәге 20 номерлы карары белән расланган «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм молкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук «Каенлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар,мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 6 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в)белешмә бирү чорына кадәрге календарь ел эчендә (алга таба – хисап чоры) үзе, аның ире (хатыны) һәм (яки) балигъ булмаган балалары башкарган җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыймммәтле кәгазьләр, акцияләр (катнашу өлеше, оешмаларның устав (склад) капиталларында пайлар) алуда һәр

килешү буенча үзенең чыгымнары, шулай ук аның ире (хатыны) һәм (яки) балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алар хисабына алыш-бирешләр башкарылган акча алу чыганаклары турында.».

1.2. Нигезләмәнең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тәкъдим ителгәнҗир кишәрлеген, башка күчемсез милек объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (катнашу өлеше, оешмаларның устав (склад) капиталларында пайларны) сатып алу буенчаалар хисабына алыш-бирешләр башкарылган (алыш-биреш башкарылган) акча алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда муниципаль вазыйфаяисә муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыручы (биләүче) затның һәм аның хатынының (иренең)гомуми кеременнән артып китсә, федераль законнар нигезендә урнаштырыла.».

1.3. Нигезләмәнең 16 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны тапшырмау,әгәр мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри булса, яисә дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат бирү муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып торган очракта.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Каенлы авыл җирлеге башлыгы Ф.М. Набиуллин